ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КУРАЛОВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

# КАРАР

№8 27.03.2025

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Куралово авыл җирлеге башкарма комитетының «Социаль наем шартнамәсе буенча Торак урын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 25 октябрендәге 37 номерлы карары белән расланган административ регламентка үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Куралово авыл җирлегенең норматив хокукый актларын гамәлдәге законнарга туры китерү сәбәпле Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Куралово авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. «Социаль наем шартнамәсе буенча торак урын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 25 октябрендәге 37 номерлы Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Куралово авыл җирлеге башкарма комитетының карары белән расланган административ регламентка түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.5 өлешендәге 2.5.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.5.3. Әгәр хисап чоры дәвамында гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан-мөрәҗәгать итүче тарафыннан салым салынырга тиешле һәм гражданнарны наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар дип тану өчен исәпкә алына торган мөлкәт исемлегенә керүче мөлкәт сатылган булса, сатылган мөлкәтнең хакы хисап чоры дәвамында булган мөлкәтнең хакы буларак исәпкә алына, моңа гариза бирүче гражданнар тарафыннан тапшырыла торган тиешле документлар белән расланган мәҗбүри сату (ашыгыч медицина дәвалануы, кыйммәтле дарулар һәм башкалар) очраклары керми.».

2. Әлеге карарны ТР Спас муниципаль районының рәсми сайтында http://spasskiy.tatarstan.ru һәм хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

ТР Спас муниципаль районының
Куралово авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе М.Н.Федотова